СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-60, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**09 октябрь, 2024 ел** **№ 451**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен премияләү турында» 2023 елның 28 февралендәге 276 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2023 елның 28 февралендәге 276 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләрен премияләү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.1 подпунктындагы таблицадагы «Түләү күләме, вазыйфаи окладтан %ларда» баганасының «Автомобиль йөртүче» юлында «130» санын «230» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов